**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары (муниципаль тур, 2017-2018 уку елы) 9 нчы сыйныф**

**Башкару вакыты – 180 минут**
**Гомуми балл - 100**

## I. Теоретик биремнәр (35 балл).

1. Түбәндә тәкъдим ителгән әсәрләрнең авторын, төрен һәм жанрын билгеләгез (20 балл):

*“Гыйлемлек хак рәхмәтедер...” яки “Игенчегә Хак рәхмәте...”;*
*“Төхфәи мәрдан”;*
*“Хөсрәү вә Ширин”;*
*“Шәмдәлләрдә генә утлар яна”;*
*“Кыйссаи Йосыф”.*

2. Ф.Кәримнең “Сибәли дә сибәли” шигыреннән алынган әлеге өзекнең нинди үлчәмдә язылганлыгын билгеләгез (5 балл):

*Төнге җилдә көзге яңгыр*
*Сибәли дә сибәли;*
*Янымдагы иптәш кенә*
*Миңа берни сөйләми...*

3. Әлеге билгеләмәләрдән әдәбият тарихы төшенчәсенә туры килгәнен сайлап алыгыз (5 балл):

*1) әдәбиятны үсеш-үзгәрештә, үзенә хас закончалыклары булган процесс буларак өйрәнә торган фән;*
*2) әдәби тәнкыйтьне үсеш-үзгәрештә, үзенә хас закончалыклары булган процесс буларак өйрәнә торган фән;*
*3) әдәби әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларны үсеш-үзгәрештә, үзенә хас закончалыклары булган процесс буларак өйрәнә торган фән;*
*4) әдәби геройларны үсеш-үзгәрештә, үзенә хас закончалыклары булган процесс буларак өйрәнә торган фән.*

4. Урта гасыр төрки-татар әдәбиятында гашыйкларның мәхәббәт көчен тасвирлауда нинди әдәби алым еш кулланыла (5 балл):

*А) пейзаж;*
*Б) гипербола, чиктән тыш арттыру;*
*В) психологик анализ;*
*Г) портрет.*

## II. Әдәби иҗатка караган биремнәр (45 балл).

1. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” яки Котбның “Хөсрәү вә Ширин” әсәрендә Йосыф-Зөләйха яки Ширин-Фәрхад мәхәббәт тарихы ничек тәмамлана? (5 балл)

2. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” яки Котбның “Хөсрәү вә Ширин” әсәрендә әдип ни өчен төп геройларын төрле авырлыклар алдына куеп сыный дип уйлыйсыз? (10 балл)

3. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” яки Котбның “Хөсрәү вә Ширин” әсәрендә автор ни өчен мәхәббәтне илаһилаштыра дип уйлыйсыз? Үз фикерегезне дәлилләп бирегез (15 балл)

4. Ни өчен әсәр бүген дә актуальлеген югалтмаган дип санныйсыз? (үзегез сайлап алган әсәр мисалында аңлатыгыз) (15 балл)

**III. Иҗади бирем (20 балл).**

1. Мәхәббәт көче турында кечкенә генә хикәя языгыз.